ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.09.2019 с.Старое Дрожжаное № 394

Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә), индивидуаль эшмәкәрләргә, физик затларга - товар, эш, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга - товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 3.1.5 – 3.1.6 пунктларын өстәргә:

«3.1.5. Югары технологияле чит ил җиһазларын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (җибәргәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган, шулай ук әлеге чараларны норматив хокукый актларда, күрсәтелгән юридик затларга субсидияләр бирүне җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка операцияләр башкару максатларына ирешүгә бәйле операцияләрдән тыш, алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән сатып алмаска.

3.1.6. Предприятие тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә финанс бүлегенә һәм муниципаль финанс тикшерүе органнарына ризалык бирергә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Башкарма комитет җитәкчесе Д. Ә. Сатдинов